ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕМЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Г.Тукая, д.35, д. Шемяк,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422140

Г.Тукай ур., 35 нче а йорт, Шәмәк авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-68-37; e-mail: Shmk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

№ 14 «22» ноября 2018 г.

2018 елның «18» ноябреннән референдумны гамәлгә ашыру максатларында чаралар планын раслау турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында» 928 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карары, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

К А Р А Р  Б И Р Д Е:

1. 2018 елның «18» ноябреннән референдумны гамәлгә ашыру максатларында кушымтада бирелгән чаралар планын расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, интернет мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитеты /И.Н.Зыятдинов/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитетының _________ 2018 ел № 14 карарына 1 нче Кушымта

**2018 елның «18» ноябреннән референдумны гамәлгә ашыру максатларында чаралар планы**

| № п/п | чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Үзара салым акчаларын түләү өчен авыл җирлеге гражданнары исемлеген әзерләү | 3 декабрьгә кадәр | Авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 2. | Гражданнарга үзара салым акчаларын түләү тәртибе турында хәбәр | 10 декабрьгә кадәр | Авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 3. | Үзара салым акчаларын җыю | 28.02.2019 кадәр | Авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 4. | Гражданнарның үзара салым акчасын исәпләп чыгаруның дөреслеген, аларның тулысынча һәм вакытында түләнүен тикшереп тору | даими | Авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 5. | Бирелгән мәгълүматлар буенча үзара салым буенча недоимка торышын анализлау | Үз вакытында | Авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 6. | 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларга чыгымнар сметасын раслау | эш тәртибендә, 2019 елның 15 апреленә кадәр | Авыл җирлегенең башкарма комитеты Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасы |
| 7. | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына гражданнар акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә | агымдагы финанс елының I кварталы тәмамланганнан соң 15 календарь көн эчендә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 1 нче кушымта нигезендә форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка бирү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы раславы | | |
| 8. | Акчаны максатчан кулллануны контрольдә тоту | Ел дәвамында | “ТР Мамадыш муниципаль районы» Контроль-хисап палатасы " МКУ |
| 9. | Авыл җирлеге башлыгының Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турында хисабы | Елга бер тапкыр | Авыл җирлеге башлыгы |
| 10. | Авыл җирлеге башлыгының Җирле референдум карары белән аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм (яки) Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турындагы хисабын игълан итү | 5 көн эчендә | Авыл җирлеге башлыгы |